# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# БОРДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«27» август 2026 г. № 7

«Белешмә биру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 4 декабрендәге 22 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Белешмә биру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 4 декабрендәге 22 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 бүлегенең 2.5.1 статьясы 4 пунктчасын түбәндәге эчтәлектә яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләрен биру һәм аларны эшкәртү кирәк булган очракта, әгәр федераль закон нигезендә мондый шәхси белешмәләрне эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булса, дәүләт яисә муниципаль хезмәтне алуны сорап мөрәҗәгать иткәндә, мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән затның яки аның законлы вәкиленең күрсәтелгән затның шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын алуын раслый торган өстәмә документлар тапшыра. Ризалык алуны раслый торган документлар шул исәптән электрон документ формасында тапшырылырга мөмкин. Әлеге өлешнең гамәлдә булуы хәбәрсез югалган дип танылган затларга һәм урнашу урыны башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы тарафыннан билгеләнмәгән эзләнүче затларга кагылмый.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), махсус стендларда һәм tukay.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Н. Абдульманова